**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об инвестиционной деятельности в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 ноября 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 ноября 1998 года № 1872 «Об инвестиционной деятельности в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 19 ноября 2020 года № 72-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 12; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2020, № 87 (часть I) следующие изменения:

1) подпункт «б» пункта 5 части 1 статьи 2 изложить в следующей редакции:

«б) не менее 90 процентов ежегодной выручки организации составляет выручка, полученная ею от реализации инвестиционного проекта на стадии эксплуатации созданных (построенных) либо реконструированных и (или) модернизированных объектов недвижимого имущества и (или) комплекса объектов движимого и недвижимого имущества, связанных между собой, и (или) использования созданных результатов интеллектуальной деятельности и (или) приравненных к ним средств индивидуализации;»;

2) в статье 3:

а) в части 1:

дополнить пунктом $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$) утверждение порядка возврата российскому юридическому лицу, отвечающему признакам организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, заявления о заключении соглашения о защите и поощрении капиталовложений, прилагаемых к нему документов и материалов в случаях, указанных в части 22

статьи 16 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации»;»;

пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3) утверждение порядка осуществления мониторинга исполнения условий соглашения о защите и поощрении капиталовложений и условий реализации инвестиционного проекта, в отношении которого заключено такое соглашение, в том числе этапов реализации инвестиционного проекта, в соответствии с общими требованиями, установленными Правительством Российской Федерации;»;

пункт 5 изложить в следующей редакции:

«5) утверждение порядка возмещения затрат, предусмотренных частью 1 статьи 9 настоящего Закона, понесенных организацией, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, в соответствии с общими требованиями, утвержденными Правительством Российской Федерации;»;

б) пункт 2 части 2 признать утратившим силу;

3) статью 9 изложить в следующей редакции:

«Статья 9. **Меры государственной поддержки инвестиционных проектов, осуществляемых в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений**

1. Организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, может быть предоставлена мера государственной поддержки, предусматривающая возмещение затрат в соответствии с бюджетным законодательством Российской Федерации и (или) налоговый вычет в соответствии с законодательством Российской Федерации о налогах и сборах:

1) на создание (строительство) либо реконструкцию и (или) модернизацию объектов обеспечивающей и (или) сопутствующей инфраструктур, необходимых для реализации инвестиционного проекта, в том числе на реконструкцию объектов инфраструктуры, находящихся в государственной (муниципальной) собственности или собственности регулируемых организаций (включая затраты на технологическое присоединение (примыкание) к инженерным и транспортным сетям);

2) на уплату процентов по кредитам и займам, купонного дохода по облигационным займам, привлеченным для создания (строительства) либо реконструкции и (или) модернизации объектов обеспечивающей и (или) сопутствующей инфраструктур, необходимых для реализации инвестиционного проекта, в том числе на реконструкцию объектов инфраструктуры, находящихся в государственной (муниципальной) собственности;

3) на уплату процентов по кредитам и займам, купонного дохода по облигационным займам, привлеченным для реализации инвестиционного проекта в части создания (строительства) новых либо реконструкции и (или) модернизации существующих объектов недвижимого имущества и (или) комплекса объектов движимого и недвижимого имущества, связанных между собой, и (или) в части

создания результатов интеллектуальной деятельности и (или) приравненных к ним средств индивидуализации, если уплата таких процентов была осуществлена на инвестиционной стадии, при условии, что в отношении таких кредитов и займов, включая облигационные займы, не предоставляются иные меры государственной поддержки;

4) на научные исследования и (или) опытно-конструкторские разработки, результатом проведения которых является создание новой технологии, при одновременном выполнении следующих условий:

а) осуществлена государственная регистрация разработанной новой технологии как результата интеллектуальной деятельности, правообладателем такой технологии является организация, реализующая инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений;

б) на основе разработанной новой технологии организацией, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, осуществляется серийное производство промышленной продукции в рамках реализации инвестиционного проекта;

в) перечень возмещаемых видов затрат определяется на основании предусмотренных подпунктами 2, 3, 4 и 5 пункта 2 статьи 262 Налогового кодекса Российской Федерации расходов на научные исследования и (или) опытно-конструкторские разработки;

г) не менее 80 процентов совокупной ежегодной выручки организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, по инвестиционному проекту в течение срока возмещения затрат, предусмотренного частями 6 и 7 статьи 15 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации», составляет выручка от реализации промышленной продукции, произведенной на основе разработанной новой технологии;

5) на демонтаж объектов, расположенных на территориях военных городков (в части жилищного строительства), при одновременном выполнении следующих условий:

а) уполномоченным федеральным органом исполнительной власти, в ведении которого находятся указанные объекты, принято решение об их передислокации;

б) за счет средств организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, осуществлены мероприятия по передислокации указанных объектов, в том числе при необходимости выполнен демонтаж таких объектов;

в) новые объекты на территориях военных городков оформлены в собственность Российской Федерации;

г) объем капитальных вложений по инвестиционному проекту составляет не менее 10 миллиардов рублей.

2. Указанная в части 1 настоящей статьи мера государственной поддержки предоставляется в форме субсидии в соответствии с бюджетным законодательством Российской Федерации и (или) в иной форме, предусмотренной законодательством Российской Федерации о налогах и сборах. Организация, реализующая инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите

и поощрении капиталовложений, осуществляет выбор формы предоставления такой меры государственной поддержки и указывает выбранную форму в расчете объема возмещения затрат, предусмотренном пунктом 5 части 5 настоящей статьи.

3. Если инвестиционный проект предусматривает создание (строительство) либо реконструкцию и (или) модернизацию объекта транспортной, энергетической, коммунальной, социальной или цифровой инфраструктуры в качестве основного объекта инвестиционного проекта (при этом под основным объектом инвестиционного проекта понимается объект транспортной, энергетической, коммунальной, социальной или цифровой инфраструктуры, ежегодная выручка от эксплуатации которого в виде предоставления возмездного доступа к его инфраструктуре (товарам, услугам) физическим или юридическим лицам составляет не менее 80 процентов общей выручки, полученной организацией, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, в связи с осуществлением инвестиционного проекта в течение срока возмещения затрат, определяемого в соответствии с частями 6 и 7 статьи 15 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации»), то возмещаются следующие затраты:

1) затраты, предусмотренные пунктами 3 – 5 части 1 настоящей статьи;

2) затраты, предусмотренные пунктами 1 и 2 части 1 настоящей статьи, в отношении объектов инфраструктуры, которые не относятся к основному объекту инвестиционного проекта и которые для целей возмещения затрат, предусмотренных пунктами 1 и 2 части 1 настоящей статьи, считаются объектами обеспечивающей и (или) сопутствующей инфраструктур.

4. Предельный объем возмещаемых затрат, указанных в части 1 настоящей статьи, и предельный срок, в течение которого возмещаются указанные затраты, не могут превышать объемы и сроки, предусмотренные частями 4 – 7 статьи 15 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации».

5. Возмещение затрат, указанных в части 1 настоящей статьи, осуществляется при одновременном соблюдении следующих условий:

1) все имущественные права, возникшие в рамках реализации инвестиционного проекта и подлежащие государственной регистрации, зарегистрированы в соответствии с законодательством Российской Федерации, осуществлена государственная регистрация результатов интеллектуальной деятельности и (или) приравненных к ним средств индивидуализации (если применимо), а также все объекты недвижимого имущества созданы (построены) либо реконструированы, если инвестиционным проектом предполагается создание (строительство) либо реконструкция объектов недвижимого имущества, и введены в эксплуатацию в соответствии с законодательством Российской Федерации;

2) у организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, отсутствует задолженность по уплате обязательных платежей, исчисленных такой организацией для уплаты в бюджет Республики Татарстан, являющейся стороной соглашения о защите и поощрении капиталовложений, в связи с реализацией инвестиционного

проекта, а именно налога на прибыль организаций, налога на имущество организаций, транспортного налога;

3) соблюдены нормативы возмещения затрат, указанных в части 1 настоящей статьи, которые предусмотрены порядком возмещения затрат, утверждаемым в соответствии с пунктом 7 части 1 статьи 4 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации»;

4) в результате проведения научных исследований и (или) опытно-конструкторских разработок создана новая технология и осуществляется серийное производство промышленной продукции на основе разработанной новой технологии, осуществлена государственная регистрация такой технологии как результата интеллектуальной деятельности, а также выполнены иные условия, предусмотренные пунктом 4 части 1 настоящей статьи (если применимо);

5) организацией, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, представлен расчет объема возмещения затрат, указанных в части 1 настоящей статьи, в соответствии с установленной Правительством Российской Федерации формой такого расчета, который в том числе предусматривает условия, указанные в пункте 5 части 9 статьи 15 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации»;

6) представлено положительное заключение о проведении государственной экспертизы проектной документации и проверки достоверности определения сметной стоимости объектов недвижимости (капитального строительства) и линейных объектов, подлежащих созданию (строительству) либо реконструкции в рамках инвестиционного проекта;

7) представлено заключение о проведении технологического и ценового аудита, выданное экспертной организацией в соответствии с требованиями к такому заключению и экспертной организации, установленными Правительством Российской Федерации, подтверждающее в том числе расчет объема возмещения затрат, подготовленный организацией, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений;

8) представлены документы, подтверждающие соблюдение организацией, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, условий, предусмотренных пунктом 5 части 1 настоящей статьи (если применимо);

9) в случае предоставления других мер прямой государственной финансовой поддержки в отношении инвестиционного проекта возмещение затрат, предусмотренных частью 1 настоящей статьи, может осуществляться в размере, не превышающем предельный объем таких затрат, определенный в соответствии с частью 4 статьи 15 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации», за вычетом других предоставленных мер прямой государственной финансовой поддержки.

6. Возмещение затрат, указанных в пунктах 1 и 2 части 1 настоящей статьи, может осуществляться по завершении отдельных этапов реализации инвестиционного проекта, предусмотренных соглашением о защите и поощрении капиталовложений. Отдельный этап реализации инвестиционного проекта считается

завершенным, если такое соглашение предусматривает несколько этапов реализации инвестиционного проекта и при этом:

1) завершено создание (строительство) либо реконструкция и (или) модернизация объекта (объектов) недвижимого имущества по отдельному этапу, такие объекты введены в эксплуатацию в соответствии с законодательством Российской Федерации и в отношении данных объектов зарегистрировано право собственности организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, либо такой объект передан (такие объекты переданы) в государственную (муниципальную) собственность или в собственность регулируемой организации;

2) после создания (строительства) либо реконструкции и (или) модернизации объекта (объектов) недвижимого имущества такой объект может (такие объекты могут) эксплуатироваться независимо от иных объектов недвижимого имущества, создание (строительство) либо реконструкция и (или) модернизация которых предусмотрены соглашением о защите и поощрении капиталовложений, для производства товаров, выполнения работ или оказания услуг, предусмотренных указанным соглашением.

7. Возмещение затрат, указанных в пунктах 1 и 2 части 1 настоящей статьи, по завершении отдельного этапа реализации инвестиционного проекта в соответствии с частью 6 настоящей статьи осуществляется в отношении объектов обеспечивающей и (или) сопутствующей инфраструктур, необходимых для эксплуатации построенного, реконструированного и (или) модернизированного на отдельном этапе объекта недвижимого имущества, в случае соблюдения условий, предусмотренных пунктами 2, 3, 5 – 8 части 5 настоящей статьи. Сроки, указанные в частях 6 и 7 статьи 15 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации», исчисляются со дня начала возмещения затрат, указанных в пунктах 1 и 2 части 1 настоящей статьи, в отношении всех объектов обеспечивающей и (или) сопутствующей инфраструктур, необходимых для эксплуатации построенного, реконструированного и (или) модернизированного на отдельном этапе объекта (объектов) недвижимого имущества.

8. Организация, реализующая инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, может воспользоваться правом на возмещение затрат, указанных в части 1 настоящей статьи, в срок, не превышающий трех лет со дня, когда все имущественные права, возникшие в рамках реализации инвестиционного проекта и подлежавшие государственной регистрации, зарегистрированы в соответствии с законодательством Российской Федерации, осуществлена государственная регистрация результатов интеллектуальной деятельности и (или) приравненных к ним средств индивидуализации (если применимо), а также все объекты недвижимого имущества созданы (построены) либо реконструированы и (или) модернизированы, если инвестиционным проектом предполагается создание (строительство) либо реконструкция и (или) модернизация объектов недвижимого имущества, и введены в эксплуатацию в соответствии с законодательством Российской Федерации. Организация, реализующая инвестиционный проект,

осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, может воспользоваться правом на возмещение затрат, указанных в части 1 настоящей статьи, по завершении отдельных этапов реализации инвестиционного проекта в срок, не превышающий трех лет со дня государственной регистрации прав на объекты недвижимости, созданные (построенные) либо реконструированные и (или) модернизированные на соответствующем этапе, при соблюдении условий, предусмотренных частями 6 и 7 настоящей статьи.

9. Организации, реализующие инвестиционный проект и заключившие соглашение о защите и поощрении капиталовложений в порядке частной проектной инициативы, могут заключить между собой договор о распределении затрат на объекты инфраструктуры. В случае если организации, реализующие инвестиционный проект, заключили между собой такой договор, они прикладывают копию такого договора к заявлению о заключении соглашения о защите и поощрении капиталовложений, предусмотренному статьей 7 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации», или направляют копию такого договора для изменения уже заключенного соглашения о защите и поощрении капиталовложений в порядке, предусмотренном статьей 11 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации». Организации, реализующие инвестиционный проект, могут направить копию договора о распределении затрат на объекты инфраструктуры для изменения уже заключенного соглашения о защите и поощрении капиталовложений не позднее даты возмещения затрат, указанных в части 1 настоящей статьи. Предусмотренный настоящей частью договор должен включать в себя информацию о затратах на создание (строительство) либо реконструкцию и (или) модернизацию объектов обеспечивающей и (или) сопутствующей инфраструктур каждой из организаций, реализующих инвестиционный проект. Затраты, указанные в части 1 настоящей статьи, возмещаются каждой организации, реализующей инвестиционный проект и заключившей договор о распределении затрат на объекты инфраструктуры, отдельно в размере понесенных такой организацией затрат, факт осуществления которых подтвержден в порядке, установленном Правительством Российской Федерации.

10. В целях возмещения затрат организация, реализующая инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, направляет в уполномоченный Кабинетом Министров Республики Татарстан орган исполнительной власти Республики Татарстан расчет объема возмещения затрат, положительное заключение о проведении государственной экспертизы проектной документации и проверки достоверности определения сметной стоимости объектов недвижимости (капитального строительства) и линейных объектов, положительное заключение технологического и ценового аудита, предусмотренные пунктами 5 – 7 части 5 настоящей статьи, а также иные документы, перечень и состав которых устанавливаются в порядке возмещения затрат, утверждаемом в соответствии с пунктом 7 части 1 статьи 4 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации».

11. Уполномоченный Кабинетом Министров Республики Татарстан орган исполнительной власти Республики Татарстан осуществляет проверку документов, предусмотренных частью 10 настоящей статьи, на предмет их комплектности в соответствии с порядком возмещения затрат, утверждаемым в соответствии с пунктом 7 части 1 статьи 4 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации».

12. Возмещение указанных в пунктах 1 и 2 части 1 настоящей статьи затрат на объекты сопутствующей инфраструктуры осуществляется в случае, если объекты сопутствующей инфраструктуры соответствуют критериям, предусмотренным пунктом 13 части 1 статьи 2 Федерального закона «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации».

13. При принятии решения о возмещении затрат, указанных в пунктах 1 и 2 части 1 настоящей статьи, должны быть определены источники финансового обеспечения затрат Республики Татарстан (муниципального образования) на обслуживание, содержание, эксплуатацию (с возможностью ликвидации) объектов сопутствующей инфраструктуры, создаваемой в рамках реализации инвестиционного проекта, передаваемых в государственную (муниципальную) собственность или поступающих в собственность регулируемой организации. При возмещении затрат, понесенных в целях создания (строительства) либо реконструкции и (или) модернизации объектов сопутствующей инфраструктуры, должно быть определено лицо, в собственность которого поступает объект сопутствующей инфраструктуры. На передачу указанного объекта в государственную (муниципальную) собственность или в собственность регулируемой организации требуется согласие Республики Татарстан (муниципального образования) либо регулируемой организации. Такое согласие может быть выражено в договоре (соглашении), предусмотренном частью 14 настоящей статьи.

14. Особенности эксплуатации и (или) передачи объектов сопутствующей инфраструктуры в государственную (муниципальную) собственность или в собственность регулируемой организации, затраты в отношении которых подлежат возмещению в соответствии с Федеральным законом «О защите и поощрении капиталовложений в Российской Федерации» и настоящим Законом, устанавливаются договором (соглашением) между организацией, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, и Республикой Татарстан (муниципальным образованием) или регулируемой организацией, в собственность которых передается (поступает) созданный объект сопутствующей инфраструктуры для дальнейшей эксплуатации. Передача объектов сопутствующей инфраструктуры в государственную (муниципальную) собственность осуществляется на основании подписываемого сторонами акта приема-передачи.

15. Допускается предоставление меры государственной поддержки, указанной в части 1 настоящей статьи, в отношении объектов инфраструктуры, включенных в инвестиционные программы регулируемых организаций, финансовое обеспечение которых полностью или частично осуществляется за счет средств организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о

защите и поощрении капиталовложений. В таком случае объем возмещаемых затрат, указанных в части 1 настоящей статьи, не может превышать 50 процентов фактически понесенных затрат организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, на финансовое обеспечение инвестиционной программы для объектов обеспечивающей инфраструктуры и 100 процентов фактически понесенных затрат организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, на финансовое обеспечение инвестиционной программы для объектов сопутствующей инфраструктуры.

16. Организации, реализующей инвестиционный проект, осуществляемый в рамках соглашения о защите и поощрении капиталовложений, могут быть предоставлены меры поддержки (в том числе меры государственной поддержки), не предусмотренные настоящей статьей. При этом объем мер государственной поддержки, за исключением объема меры государственной поддержки, указанной в части 1 настоящей статьи, не должен превышать объем капитальных вложений, направляемых на реализацию нового инвестиционного проекта, в отношении которого заключено соглашение о защите и поощрении капиталовложений.»;

4) в статье 13:

а) в абзаце первом слова «Налоговые льготы» заменить словами «1. Налоговые льготы»;

б) дополнить частью 2 следующего содержания:

«2. Субъектам инвестиционной деятельности, реализующим инвестиционные проекты по строительству (реконструкции, модернизации) генерирующих объектов, функционирующих на основе использования отходов производства и потребления, отобранные по результатам конкурса, проведенного в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации от 27 декабря 2010 года № 1172 «Об утверждении Правил оптового рынка электрической энергии и мощности и о внесении изменений в некоторые акты Правительства Российской Федерации по вопросам организации функционирования оптового рынка электрической энергии и мощности», налоговые льготы могут предоставляться на срок до 15 лет с момента ввода объекта в эксплуатацию.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казань, Кремль
11 декабря 2021 года
№ 88-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктының «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) оешманың еллык кеременнән кимендә 90 процентын аның булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектларыннан һәм (яисә) үзара бәйле булган күчемле мөлкәт һәм күчемсез мөлкәт объектлары комплексыннан файдалану стадиясендә инвестиция проектын гамәлгә ашырудан һәм (яисә) интеллектуаль эшчәнлекнең булдырылган нәтиҗәләреннән һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чараларыннан файдаланудан алынган кереме тәшкил итә;»;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$) «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 16 статьясындагы 22 өлешендә күрсәтелгән очракларда, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакында килешү төзү турындагы гаризаны, аңа кушып бирелә торган документларны һәм материалларны капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма билгеләренә туры килүче Россия юридик затына кире кайтару тәртибен раслау;»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү шартларын һәм үзенә карата мондый килешү төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру, шул исәптән аны башкару этапларын гамәлгә ашыру, шартларын үтәүне мониторинглауны башкару тәртибен раслау;»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган гомуми таләпләр нигезендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма тарафыннан тотылган, әлеге Законның 9 статьясындагы 1 өлешендә каралган чыгымнарны каплау тәртибен раслау;»;

б) 2 өлешнең 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чаралары**

1. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешмага Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә чыгымнарны каплауны һәм (яисә) салымнар һәм җыемнар хакындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнгән салымны кайтаруны күздә тоткан дәүләт ярдәме чарасы түбәндәге чыгымнарга бирелергә мөмкин:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыруга (төзүгә) йә реконструкцияләүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә, шул исәптән дәүләт (муниципаль) милкендәге яисә җайга салына торган оешмалар милкендәге инфраструктура объектларын реконструкцияләүгә (инженерлык һәм транспорт челтәрләренә технологик тоташтыру (тоташу) чыгымнарын да кертеп);

2) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү өчен җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентларны, облигация заемнары буенча купон керемен түләүгә, шул исәптән дәүләт (муниципаль) милкендәге инфраструктура объектларын реконструкцияләүгә;

3) инвестиция проектын яңа күчемсез мөлкәт объектларын һәм (яисә) үзара бәйле булган күчемле мөлкәт һәм күчемсез мөлкәт объектлары комплексын булдыру (төзү) йә гамәлдәгеләрен реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чараларын булдыру өлешендә гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентларны, облигация заемнары буенча купон керемен түләүгә, мондый процентлар инвестиция стадиясендә түләнгән булса

һәм мондый кредитларга һәм заемнарга, облигация заемнарын да кертеп, дәүләт ярдәменең башка чаралары бирелмәгән булса;

4) аларны үткәрү нәтиҗәсендә яңа технология барлыкка килгән фәнни тикшеренүләргә һәм (яисә) тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренә, түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгән очракта:

а) интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе буларак эшләнгән яңа технология дәүләт теркәвенә алынган булса, мондый технология хокукына капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма ия булса;

б) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма тарафыннан инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында эшләнгән яңа технология нигезендә сәнәгать продукциясен серияле җитештерү гамәлгә ашырылса;

в) чыгымнарның каплана торган төрләре исемлеге Россия Федерациясе Салым кодексының 262 статьясындагы 2 пунктының 2, 3, 4 һәм 5 пунктчаларында каралган фәнни тикшеренүләргә һәм (яисә) тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренә чыгымнар нигезендә билгеләнсә;

г) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләрендә каралган чыгымнарны каплау срогы дәвамында инвестиция проекты буенча еллык гомуми кеременнән кимендә 80 процентын эшләнгән яңа технология нигезендә җитештерелгән сәнәгать продукциясен сатудан алган табыш тәшкил итсә;

5) хәрби шәһәрчекләр территорияләрендәге объектларны сүтүгә (торак төзелеше өлешендә), түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгәндә:

а) вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан аның карамагындагы күрсәтелгән объектларны яңадан урнаштыру турында карар кабул ителсә;

б) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма акчалары исәбеннән әлеге объектларны яңадан урнаштыру чаралары гамәлгә ашырылса, шул исәптән, кирәк булганда, мондый объектларны сүтү эшләре башкарылса;

в) хәрби шәһәрчекләр территорияләрендәге яңа объектлар Россия Федерациясе милкенә рәсмиләштерелгән булса;

г) инвестиция проекты буенча капитал салулар күләме кимендә 10 миллиард сум тәшкил итсә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасы Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә субсидия рәвешендә һәм (яисә) салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган башка рәвештә бирелә. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма мондый дәүләт ярдәме чарасын бирү рәвешен сайлый һәм сайланган

рәвешне әлеге статьяның 5 өлешендәге 5 пунктында каралган чыгымнарны каплау күләмен исәпләүдә күрсәтә.

3. Инвестиция проекты аның төп объекты буларак транспорт, энергетика инфраструктурасы объектын, коммуналь, социаль яисә цифрлы инфраструктура объектын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне һәм (яисә) модернизацияләүне күздә тотса (инвестиция проектының төп объекты дигәндә, транспорт, энергетика инфраструктурасы объекты, коммуналь, социаль яисә цифрлы инфраструктура объекты аңлашыла, аннан физик яисә юридик затларга объектның инфраструктурасыннан (товарларыннан, хезмәт күрсәтүләреннән) түләүле файдалана алу мөмкинлеген бирү рәвешендә файдаланудан еллык керем капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә билгеләнә торган чыгымнарны каплау срогы дәвамында инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә алган гомуми кеременнән кимендә 80 процентын тәшкил итә), түбәндәге чыгымнар каплана:

1) әлеге статьяның 1 өлешендәге 3 – 5 пунктларында каралган чыгымнар;

2) инвестиция проектының төп объектына керми торган һәм әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында каралган чыгымнарны каплау максатларында тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектлары булып санала торган инфраструктура объектларына карата әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында каралган чыгымнар.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән каплана торган чыгымнарның иң чик күләме һәм шушы чыгымнар каплануның иң чик срогы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган күләмнәрдән һәм сроклардан артык була алмый.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгәндә гамәлгә ашырыла:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында барлыкка килгән һәм дәүләт теркәвенә алынырга тиешле барлык мөлкәти хокуклар Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чаралары (кулланып булган очракта) дәүләт теркәвенә алынган, шулай ук, әгәр инвестиция проекты күчемсез мөлкәт объектларын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне күздә тоткан очракта, аларның бөтенесе дә булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануга тапшырылган булса;

2) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың, инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүнең бер ягы булган Татарстан Республикасы бюджетына түләү өчен мондый оешма тарафыннан исәпләнгән мәҗбүри түләүләрне, аерым алганда, оешмалар табышына салымны, оешмалар мөлкәтенә салымны, транспорт салымын түләү буенча бурычы булмаса;

3) «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибе белән каралган әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау нормативлары үтәлгән булса;

4) фәнни тикшеренүләр һәм (яисә) тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләре үткәрү нәтиҗәсендә яңа технология булдырылган һәм эшләнгән яңа технология нигезендә сәнәгать продукциясен серияле җитештерү гамәлгә ашырылса, мондый технология интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе буларак дәүләт теркәвенә алынган, шулай ук әлеге статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында каралган башка шартлар үтәлгән булса (кулланып булган очракта);

5) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау күләмен исәпләү нигезендә, ул шул исәптән «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешенең 5 пунктында күрсәтелгән шартларны да күздә тота, шушы чыгымнарны каплау күләмен исәпләүне биргән булса;

6) инвестиция проекты кысаларында булдырылырга (төзелергә) йә реконструкцияләнергә тиешле күчемсез мөлкәт (капиталь төзелеш) объектларының һәм линия объектларының проектлау документларына һәм аларның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүгә дәүләт экспертизасы уздыру турында уңай бәяләмә бирелгән булса;

7) технологик аудит һәм бәя аудиты үткәрү турындагы бәяләмәгә һәм эксперт оешмасына карата Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләр нигезендә эксперт оешмасы тарафыннан бирелгән, шул исәптән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма әзерләгән чыгымнарны каплау күләмен исәпләүне дә күздә тоткан мондый бәяләмә бирелгән булса;

8) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма тарафыннан әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында каралган шартларны үтәүне раслаучы документлар бирелгән булса (кулланып булган очракта);

9) инвестиция проектына карата турыдан-туры дәүләт финанс ярдәменең башка чаралары бирелгән очракта, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган чыгымнарны каплау, турыдан-туры дәүләт финанс ярдәменең бирелгән башка чараларын исәпкә кертмичә, «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнгән мондый чыгымнарның иң чик күләменнән артмаган күләмдә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплау капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этаплары тәмамланганнан соң гамәлгә ашырылырга мөмкин. Инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этабы, әгәр мондый килешү инвестиция проектын башкаруның

берничә этабын күздә тотса һәм түбәндәгеләр башкарылган булса, төгәлләнгән дип санала:

1) аерым этап буенча күчемсез мөлкәт объектын (объектларын) булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү тәмамланган, мондый объектлар Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануга тапшырылган һәм әлеге объектларга карата капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың милек хокукы теркәлгән йә мондый объект (объектлар) дәүләт (муниципаль) милкенә яисә җайга салына торган оешма милкенә тапшырылган булса;

2) күчемсез мөлкәт объектын (объектларын) булдырудан (төзүдән) йә реконструкцияләүдән һәм (яисә) модернизацияләүдән соң мондый объект (объектлар), булдырылуы (төзелүе), йә реконструкцияләве һәм (яисә) модернизацияләве капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә каралган башка күчемсез мөлкәт объектларыннан бәйсез рәвештә, әлеге килешүдә каралган товарлар җитештерү, эшләр башкару яисә хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланылырга мөмкин.

7. Әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этабы тәмамланганнан соң әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплау, әлеге статьяның 5 өлешендәге 2, 3, 5 – 8 пунктларында каралган шартлар үтәлгән очракта, аерым этапта төзелгән, реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектыннан файдалану өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларына карата гамәлгә ашырыла. «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләрендә күрсәтелгән сроклар әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплауны башлау көненнән алып аерым этапта төзелгән, реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектыннан (объектларыннан) файдалану өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктураларның барлык объектларына карата исәпләнә.

8. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында барлыкка килгән һәм дәүләт теркәвенә алынырга тиешле барлык мөлкәти хокуклар Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чаралары (кулланып булган очракта) дәүләт теркәвенә алынган, шулай ук, әгәр инвестиция проекты күчемсез мөлкәт объектларын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне һәм (яисә) модернизацияләүне күздә тоткан очракта, аларның бөтенесе дә булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануга тапшырылган көннән алып өч елдан да артмаган срокка әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау хокукыннан файдалана ала. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын

башкаручы оешма, әлеге статьяның 6 һәм 7 өлешләрендә каралган шартлар үтәлгән очракта, инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этаплары тәмамланганнан соң тиешле этапта булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар дәүләт теркәвенә алынган көннән алып өч елдан да артмаган срокка әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау хокукыннан файдалана ала.

9. Инвестиция проектын гамәлгә ашыручы һәм хосусый проект инициативасы тәртибендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзегән оешмалар инфраструктура объектларына чыгымнарны бүлү хакында үзара килешү төзи алалар. Инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешмалар үзара шундый килешү төзегән очракта, алар мондый шартнамәнең күчермәсен «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 7 статьясында каралган капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакында килешү төзү турындагы гаризага кушып бирәләр яисә инде төзелгән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешүне үзгәртү өчен мондый шартнамәнең күчермәсен «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 11 статьясында каралган тәртиптә җибәрәләр. Инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешмалар, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау датасыннан да соңга калмыйча, инде төзелгән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүне үзгәртү өчен инфраструктура объектларына чыгымнарны бүлү хакындагы шартнамәнең күчермәсен җибәрә алалар. Әлеге өлештә каралган шартнамәдә инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешмаларның һәрберсенең тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктура объектларын булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чыгымнары турында мәгълүмат булырга тиеш. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнар инвестиция проектын гамәлгә ашыручы һәм инфраструктура объектларына чыгымнарны бүлү хакында шартнамә төзегән һәр оешмага аның тарафыннан тотылган һәм аларны тоту факты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган чыгымнар күләмендә аерым каплана.

10. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма чыгымнарны каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына әлеге статьяның 5 өлешендәге 5 – 7 пунктларында каралган чыгымнарны каплау күләмен исәпләүне, күчемсез мөлкәт (капиталь төзелеш) объектларының һәм линия объектларының проектлау документларына һәм аларның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүгә дәүләт экспертизасы уздыру хакындагы уңай бәяләмәне, технологик аудитның һәм бәя аудитының уңай бәяләмәсен, шулай ук исемлеге һәм составы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибе белән билгеләнә торган башка документларны җибәрә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы әлеге статьяның

10 өлешендә каралган документларны, «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибенә таянып, аларның комплектлылыгы предметына тикшерә.

12. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән тиешле инфраструктура объектларына чыгымнарны каплау тиешле инфраструктура объектлары «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында каралган критерийларга туры килгән очракта гамәлгә ашырыла.

13. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплау турында карар кабул ителгәндә, инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында булдырыла торган тиешле инфраструктураның дәүләт (муниципаль) милкенә тапшырыла торган яисә җайга салына торган оешманың милкенә керә торган объектларына хезмәт күрсәтүгә, аларны карап тотуга, алардан файдалануга (аларны бетерү мөмкинлеге белән) Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганаклары билгеләнергә тиеш. Тиешле инфраструктура объектларын булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү максатларында тотылган чыгымнарны каплаганда, милкенә тиешле инфраструктура объекты керә торган зат билгеләнергә тиеш. Күрсәтелгән объектны дәүләт (муниципаль) милкенә яисә җайга салына торган оешманың милкенә тапшыру өчен Татарстан Республикасының (муниципаль берәмлекнең) яисә җайга салына торган оешманың ризалыгы таләп ителә. Мондый ризалык әлеге статьяның 14 өлешендә каралган шартнамәдә (килешүдә) белдерелергә мөмкин.

14. Үзләренә карата чыгымнар «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль закон һәм әлеге Закон нигезендә капланырга тиешле булган тиешле инфраструктура объектларыннан файдалану һәм (яисә) аларны дәүләт (муниципаль) милкенә яисә җайга салына торган оешманың милкенә тапшыру үзенчәлекләре капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма һәм булдырылган тиешле инфраструктура объекты аннан алга таба файдалану өчен үз милкенә тапшырыла торган Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) яисә үз милкенә керә торган җайга салынучы оешма арасындагы шартнамә (килешү) белән билгеләнә. Тиешле инфраструктура объектларын дәүләт (муниципаль) милкенә тапшыру яклар тарафыннан имзалана торган кабул итү-тапшыру акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасын финанс белән тәэмин ителеше капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә гамәлгә ашырыла торган җайга салынучы оешманың инвестиция программаларына кертелгән инфраструктура объектларына карата күрсәтү рөхсәт ителә. Бу очракта әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән каплана торган чыгымнар күләме капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың тәэмин итүче инфраструктура

объектлары өчен инвестиция программасын финанс белән тәэмин итүгә фактта тотылган чыгымнарының 50 процентыннан һәм капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың тиешле инфраструктура объектлары өчен инвестиция программасын финанс белән тәэмин итүгә фактта тотылган чыгымнарының 100 процентыннан артык була алмый.

16. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешмага әлеге статьяда каралмаган ярдәм чаралары (шул исәптән дәүләт ярдәме чаралары) бирелергә мөмкин. Дәүләт ярдәме чаралары күләме, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасы күләменнән тыш, үзенә карата капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзелгән яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган капитал салулар күләменнән артмаска тиеш.»;

4) 13 статьяда:

а) беренче абзацта «Салым ташламалары» сүзләрен «1. Салым ташламалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. «Электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базары кагыйдәләрен раслау турында һәм электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базарының эшләвен оештыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 27 декабрендәге 1172 номерлы карары нигезендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану нигезендә эшли торган генерация объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары объектны файдалануга тапшырган вакыттан алып 15 елга кадәр бирелергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 88-ТРЗ